## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш  авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19 ноябрь 2025 ел** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 19 ноябрендә үткәрелгән гражданнар җыенының «2026 елда 1500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш авылы территориясендә :«I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары ,Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән,  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (су башнясын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча түләү, махсус аренда.техника)

2) Чураш торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау

3) Традицион Күмү урыннарын төзекләндерү ( кыргый куаклардан чистарту өчен гербицидлар сатып алу Чураш авылы зираты)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 133 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -  70 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 70 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен  0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2026 елда 1500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш  авылы :«I группа инвалидлар , көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Карашай-Саклау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (су башнясын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча түләү, махсус аренда.техника)

2) Чураш торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау

3) Традицион Күмү урыннарын төзекләндерү ( кыргый куаклардан чистарту өчен гербицидлар сатып алу Чураш  авылы  зираты)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:  кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Карашай-Саклау  авыл җирлегенең Чураш  авылы мәгълүмати стендларына  урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Карашай-Саклау  авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче                                        В.В.Хосниева